Reviews

Бәяләмә һәм күзәтүләр

Рецензии и обзоры

# REVIEW OF THE SCIENTIFIC PUBLICATION "PAINTING IN A FAIR LIGHT: ON HISTORY OF OUR FAMOUS PEOPLE" BY M.S.MAHDIEV: JOURNALISTIC AND RESEARCH PAPERS ([COMPILED BY G.KHASANOVA]. – KAZAN: TATAR.BOOK PUB, 2014, 583P.)

**Daniya Fatikhovna Zagidullina,**
Tatarstan Academy of Sciences,
20 Bauman Str., Kazan, 420111, Russia,
zagik63@mail.ru.

The article reviews the work "Painting in a Fair Light" by Muhammet Sungatovich Mahdiev, an outstanding expert in literary studies, writer and scholar with encyclopedic knowledge. His literary work is highly appreciated as well as his scientific heritage. The review focuses on his personality and his attempt to return the cultural heritage to the nation. The author studies M.Mahdiev's academic and journalistic works and underlines his interest both in individual personalities and historical events. The works of this scholar, written in accordance with the methodology of "daily routine history", give a detailed description of the century, people's lifestyle and the image of that time. In addition, this methodology enables the scholar to examine and understand the psychological atmosphere of different centuries, the mentality of individuals and nations as well as people's feelings, dreams and goals in a certain period of time.

Highly appreciating M.Mahdiev's academic and journalistic works, the reviewer analyzes these works in historical and cultural aspects, focuses on his talent and intelligence, and traces his interests extending from the life of an individual to the history of the nation. The author believes that M.Mahdiev holds a special place in Tatar history and nation along with such outstanding Tatar scientists as Ghali Rakhim, Gaziz Gubaidulin, and Dzhamal Validi.

**Key words**: Tatar literature, "daily routine history", historical and cultural heritage of Tatars, Muhammet Sungatovich Mahdiev, academic and journalistic activity.

Cultural heritage is an unlimited and invaluable wealth, owing to which people's education, dreams, inner worlds and feelings improve and develop. Still, we need the selflessness and commitment of talented people to preserve this gem of humanity. As a part of scientific heritage, the work "Painting in a Fair Light" by Muhammet Sungatovich Mahdiev proves this idea, by showing the importance of national heritage to the whole world in spite of the difficult struggles in our lives (Mahdiev M.C. "Painting in a Fair Light": On the Lives of Our Famous People: Journalistic and Scientific Papers – Kazan: Tatar publishing house, 2014. 583 p.).

"Only fighters can advance peoples and nations". These words of M.Mahdiev from his article "The Bells of History" are still relevant as well as the destiny of "the generation of light morning frost" (Kh.Tufan's phrase), who became known to the scientific community during "Khruschev's thaw" in the 1960s. It is also true of M.Mahdiev's activity, occupation, intelligence, education, and his personal position. Thus, M.Mahdiev's scientific heritage is an example of a national attempt to return the real national history back to our people. He believed that during the Soviet era research into a certain period of national and cultural history could be attested to personal courage. This book includes a lot of information which was 'blank spots' in history for readers for a long time.

Before writing his research papers on literary issues, the author explored many facts, data, events, and fates with a view to throw light upon the history of culture at the beginning of the 20th century, which will be later known as the history of personalities who made a great contribution to the enlightenment and development of Tatar nation. The list of these personalities includes such notable representatives of "the Golden Age" as Sh.Marzhani, K.Nasiiri, G.Bayazitov and G.Rahmankoliy. The book describes the lives, fates, dreams, feelings and goals of such outstanding people as G.Tukay, F.Amirkhan, G.Kamal, Sh.Kamal, and G.Kolakhmatov, who took part in the early 20th century insurrection. The author highly estimates and thoroughly analyzes the activity of G.Rakhimov, G.Gubajdullin, Zh.Validi, G.Sagdi, and G.Nigmati in Tatar culture and science. He also notes the scientists of other nationalities who have contributed to the development of Tatar science and education. They are journalist I.N.Khoritonov (1859-1954) and lawyer A.G.Bat, who are remembered with gratitude.

To conclude, this collection, encompassing 70-80 years of history, is a national encyclopedia and a chronicle, which describes the most troubled times in the history of Tatar nation. At the same time, this is not just a book presenting historical facts, but also an assemblage of bitter destinies, difficult lives, personal aspirations alongside with a profound love for one's own nation, devotion to ideals, betrayal for the sake of friendship, denial of national ideals for the sake personal ambitions, adaptation to ideological pressure, etc.

In science, this exciting and interesting form of presenting information to readers is called "daily routine history". This methodology makes it possible to mirror and reconstruct the history of nation in daily situations, details, and pictures. This enables us to understand the cause of different events, to feel the physiological atmosphere of a certain historical period, the intellectual state and mentality of people and their nation, and to identify emotional experiences of that time. For example, the stories, included in the book, are about the lives of G.Tukay, F.Amirkhan, M.Gafuri, etc. They are like literary essays as they present the nature of the protagonists, their living area and reveal the author's critical appraisal and attitudes. That is why the story of Gabdulla Tukay's life ("Contemporaries on Gabdulla Tukay", 1962; "The Cradle of a Poet", 1976) is perceived like an ode for a countryside outside Kazan and its intellectual meaning. "Creative Works of Sultan Rakhmankoliy" (1966) and "The Rakhmankoliys in the History of Tatar Pedagogy" (1967) describe numerous works by Gabdelmannan and his son Sultan Rakhmankoliy, their activity, spiritual atmosphere in the family, their relationships, attitude to their relatives, friends, acquaintances and aristocracy, to people they were familiar with. Their books, dictionaries, and translations are also analyzed here. Thus, we can say that a generalized character of Tatar enlighteners, the character of people who go "painting in a fair light…" has been written.

When speaking on specific events or giving his own opinion of people through a situation, the author points out the ways of enriching these materials with other information and always provides a wide historical and cultural background. The article "Fatykh Amirkhan Controlled by Gendarmerie" (1976), based on documents from the Tatarstan National Archive, is the evidence of the author's thorough approach to separating fact from fiction. The described situations lead us to the personality of Fatykh's father – Zaryf Amirkhan, to the days when he was under the supervision of gendarmes, and direct us to the life story of Akhmatgaray Khasany, who is always mentioned alongside with the name of Fatykh. The relationship between the writer and M.Vakhitov is another focus of the narration. M.Mahdiev writes about Tatar intellectuals, who were under the supervision of gendarmes or taken into custody. He builds a bridge connecting the history of an individual with the nation, and, being a broad-mined intellectual, he managed to combine his talent for writing with his talent for illustration. The main idea – "my nation is not miserable" – is appreciable in every story. This is his answer to Soviet ideology and his contribution to the development of national consciousness and pride.

M.Mahdiev's works also reveal the author's personality and his broad knowledge. For example, the article "The Cradle of the Poet" contains information on different issues: ethnographic and statistic data, facts from the history of Tatar rebellion against the government and forced conversion to Christianity.as well as facts about the fight against Napoleon's army; he also writes about local occupations, merchants' ancestry and the fate of schools, intelligent people and scholars from Gabdulla Tukay's hometown, their daily labor, works of different talented people and historical events reflected in local literature, etc. As the author says, "the amber from Kazan countryside"(as the Tatar saying goes)are G.Tukay, Sh.Mardzhani's father Bahavetd in and his grandfather Gabdennasyr, G.Kursavi, A.Urazaev-Kurmashi, H.Salikhov, astronomers Khamza Barazavi, Fayzullah ibn Murtaza, enlighteners Sh.Kultasi, T.Yakhin, F.Gubaev, G.Makhmudev, K.Khalidi, Tatar musicians Kh.Gabeshi, Kh.Ahmadullin and many other personalities. Peoples' destinies are like a chain connecting the local history and the history of the whole Tatar nation.

Different parts of this work are written in a chronological order which is of great importance for readers. Articles, written between 1962-1968butpublishedin present-day newspapers and magazines, deserve special attention. For the first time M.Mahdiev published these articles when he was doing his postgraduate studies at Kazan University. Supervised by Khatip Gosman, he completed his PhD thesis "Tatar Soviet Literary Criticism (1917-1932)" and defended it in 1964. This research paper is devoted to a complicated and controversial stage in Literary Criticism.

The work of the young scholar aimed to draw attention to the Tatar literary criticism after the year of 1917. It also served the purpose of bringing many important literary names back to the contemporary literary criticism by giving a worthy estimation of their work and revealing their achievements in literature. This relevant and foundational subject-matter becomes a vital and lifelong topic of M.Mahdiev's works. He publishes informative articles based on archival and press materials of the 20th century, extending the boundaries of literary criticism. Moreover, he highlights the importance of preserving the heritage of authors and critics and passing it on to a new generation.

For instance, in his article "New Facts about Galimdzhan Nigmati" M.Mahdiev writes the following: "Unfortunately, we don't know enough about Galimdzhan Nigmati's private life and social activity; there is only one page of information about his biography in "Selected Works". The details of his social life and activity could be of great importance for reviewers of his works in the field of literature". It means that M. Mahdiev pursued a definite goal. In his numerous research works M.Mahdiev tried to justify different persons and events unfairly slandered by society.

There is another example. A three-dimensional article "Gabdrakhman Sagdi" by M.Mahdiev was published in 1964. Here, the writer describes a complicated life of the first Tatar professor-philologist G.Sagdi, his main works, expressing his appreciation of G.Sagdi's diligence. This article was his first major work after the years of persecution.

Unfortunately, after M.Mahdiev had appreciated highly and returned these names to the history of our culture, they were forgotten again during the "frosts" of the1970s. It was only in 1990, that these personalities and events came back to Tatar science. One of such issues is the history of madrasah. An article about "Galiya" madrasah was published in the journal "Soviet School" in 1967. In 1969, M.Mahdiev prepared another outstanding work on the history and shambles of "Izh-Bubi" madrasah. The book under review includes the first Russian version of this article preserved in handwriting ("A Few Facts from the History of Bobinski School").In this article, M.Mahdiev presents the arguments between him and his reviewers and shows the attitude of "Soviet censorship" to the national heritage. The book traces the history of the studies conducted on "Izh-Bubi" madrasah at the beginning of the 20th century in Tatar press and provides extensive materials on the institution, its teachers and also Gabdulla and Gubaydulla Bubi. M.Mahdiev refers to the materials stored in the Kazan Province Archives Management, namely, notebooks of students, and interrogation reports. He also used information from the research of A.H.Makhmutova. During this period, the problems of censorship, hidden research, false denunciations were solved. The work presents an attempt to reconcile the new and old forms of education as well as thorough research on the identity of Ishmi Ishan.

M.Mahdiev continued his studies of the history of Tatars' science and education to the last days of his life. He was interested in the destinies of Gubaydulla and Gubaidulla Bubi, R.Fakhretdin, Z.Kamali, G.Barudi, F.Karimiand he appreciated their work highly. The researcher collected data on the education system in large madrasahs like "Muhammad", on textbooks and curricula of schools-madrasah, and on the books by Gabdelman

Rakhmankoliy and Tajip Yakhin. Parts of his studies have been published.

Several of these individuals became the subject of his research over and over again. More than once, M.Mahdiev studied the fate of G.Tukay, F.Amirkhan, G.Rakhim, G.Gubaydullin, and S.Suanchaley. He focused on new facts and new trends in the Tatar national-cultural movements in the early 20$^{th}$ century. For example, in his major work “A Voice from Afar”, which was prepared for the 75$^{th}$ anniversary of G.Rakhim’s birth, M.Mahdiev describes the life of the great Tatar writer and scientist G.Rakhim. The publication is based on archive materials, G.Rakhim’s ethnographical and literary works, his works in literary criticism and history of literature. The writer’s tragic life, depicted with great precision, is another focus of the article. On the one hand, we can feel pride for Tatar outstanding personalities; on the other hand, we also feel the fear Soviet scientists experienced living under the conditions of ideological pressure as the revolution of 1917 brought a change and a tragedy for people, the leaders of the revolution. The article was to be published in the University collection of scientific papers in 1971, however it did not happen. Only in 1990, after the destruction of the Soviet ideology, the heritage of G.Rakhim and “the ruined fate” of Tatar intellectuals became known. M.Mahdiev raised the issue of Tatar scientific and cultural heritage and began his research into the unknown aspects of literary and scientific activity of Gali Rakhim, Dzhamal Validi, Gaziz Gubaydullin, and Fatikh Karimi.

From the mid-1970s, M.Mahdiev prepared materials of a different character. The article “Schools of Istanbul” (1977) by Fatikh Karimi was planned as a part of his doctoral thesis. For the first time in the history of Tatar literature, the travel notes of F.Karimi were comprehensively analyzed. In these materials M.Mahdiev focuses on Tatar revival, on people who studied this issue, their thoughts and ideas. In 1980, he gave his original evaluation of Mazhit Gafuri’s literary works dedicating his paper to the centenary of the great Tatar poet. “M.Gafuri’s oeuvre is based on the image of his people and the destiny of his country. Like a major thread running through his life was the idea of being inseparable from his country and the fate of his people”, said M.Mahdiev. This is the position from which he analyzed M.Gafuri’s oeuvre. The scholar also identified M.Gafuri place in Tatar literature. He defined it precisely: “…as for poetic skills, G.Tukay was ahead of his contemporary M.Gafuriand it has never been questioned in scientific research. At the same time, Mazhit Gafuri, unlike S.Ramiev, was not a representative of “ideal poetry” and Dardemand. Gafuri was a man from among the common people: apprentices, poor peasants and working people. In his poems, plaintive voices of the poor people and cries of bitter destinies were heard more often than in other writers’ works”. The article, devoted to F.Amirkhan is written in the same spirit, however, it is of a different type: its aim is to reveal the spiritual greatness of F.Amirkhan’s personality. On the one hand, the writer associates the fate of F.Amirkhan with the phrase from his own prose: “there is human existence full of happiness, but there is also human life without happiness”. He describes the tragedy of the smart, capable and intelligent Fatikh, who lost his both legs. On the other hand, as fate would have it, the writer and his creative work were highly appreciated.

In 1983, M.Mahdiev wrote an article on G.Kamal’s activity in the newspaper “Stars”, introducing him as a journalist. His works devoted to Mirgaziz Ukmasyi were published several times in press. M.Mahdiev acquainted the readers with S.Synchalai and N.Dumavi and analyzed a few of their works.

The works by M.Mahdiev are based both on materials of libraries and archives and on the information acquired through personal relationships and communication. One of them is devoted to the life of Akhmetgaray Khasani. He opened the Publishing House “Gasyrlar” (‘Century’) and, by publishing his own journal “An” (‘Cognition’), he made a great contribution to the publishing of Tatar books and the development of Tatar press. M.Mahdiev created a new image of Akhmetgaray Khasani and his assistant Zainap. While listening to Zainep Khasany, he filled out his notebook. He wrote letters to the wives of repressed men, such as Makhmut Galau’s wife Zainap, Gaziz Gubaidullin’s wife Rabiga asking for any information available about their husbands. These letters were published later, namely in 1993.

M.Mahdiev also wrote about the children’s writers F.Agiev and N.Khalfin, a highly educated and intelligent person, who wrote articles about Tatar literature and Tatar literary science, about Sadri Dzhamal, the author of the novel “On the Shore of the River Dim”and the enlightener and religious figure Gabderrashid Ibrahimov.

In his articles, M.Mahdiev describes the Soviet period and reviews the press of that time. “The Mirror of Our History” (1989), devoted to the 80$^{th}$ anniversary of the journal “Kazan Utlari” (The Lights of Kazan’) has the following lines: “We

have done enough damage. …However, there are "Shura" ('Organizations') and "An" ('Cognition') in our history, the literature, which is alive, and journalism. The longer time goes on the more we appreciate the value of these journals: it is difficult to imagine journalism and the history of literature without the activity and works of Riza Fahretdinov, Gabdulla Tukay, Dzhamal Validy, Galimzhyan Ibrahimov, Akhmetgaray Khasany, Zakir and Shakir Ramievs.

After social reorganization, M.Mahdiev's research was made public thanks to freedom of thought. At the beginning of the 20$^{th}$century his works were published as monographs, however estimated as doctoral theses. The first collection ("Literature and Reality: A New Date for Tatar Literary History at the Beginning of the 20$^{th}$ Century". Kazan: Tatar Book Publishing House, 1987. P. 304) includes his papers devoted to Tatar literature and history of culture. In 1989, M.Mahdiev completed his monograph "Towards Reality: The Issues of Reality in Tatar Literature at the Beginning of the 20$^{th}$Century". Kazan. Kazan State University publishing house, 1989. P.155). In the first part of his work "A Temporary Tatar Press as a Source for Literary History in the 1910s",the researcher reviews nearly ten newspapers and magazines released in 1910: he analyzes the themes discussed on the pages of these newspapers and magazines, and carries out a profound study of the most important and timely articles. The second part of his work is titled "Prototypes in Tatar Literature of the Early 20$^{th}$ Century. On the Importance of Their Revelation". It is the author's attempt to elaborate a new scientific trend. Using scientific methods of study, the author refers to Russian and European literature prototypes. He provides interesting information about the works of G.Ibrahimov, G.Tukay, F.Amirkhan, and M.Faizi: their history, prototypes for characters and their destinies. The third chapter of the book is devoted to such under-researched spheres as art, opera, and music of the early 20$^{th}$centuryin Tatar press. It studies Tatar culture of the early 20th century, religious and world holidays, literary-musical parties, clubs for young Tatar people, art and music for schoolchildren.

By giving various examples, the author proves that Tatar culture and literature developed their theoretical basis integrating literary processes and cultural methods. It was a great activity which was realized in Tatar press. In this part of the book, M.Mahdiev thoroughly studies Tatar culture at the beginning of the 20$^{th}$ century, analyzes religious holidays, literary-musical parties, Tatar youth clubs, which brought youth together, songs and art presented to public, the development of artistic trends and the search for certain types of art.

In 1990, as a continuation of the book, he wrote "Social Roots of a Talent" ("Social Roots of a Talent: from the History of Tatar Literature in the Revolutionary Years and during World War I". Kazan. Kazan State University publishing house, 1990. P.159) (in Russian). The book presents the history of the early 20$^{th}$century and considers different problematic aspects. The first one concerns the way events are interpreted in the world literature and journalism. The second aspect is related to the notion "common motherland" found in literary texts: the relationships between Russian and Tatar people, which leads the readers to a thought-provoking generalization. K.Nasiiri refers to the discussion of this issue in the 1913s and M.Mahdiev draws a conclusion: Tatar people have grown out of "Musulmanizm" and have learned to accept people not as Muslims or Christians but as representatives of a nation. The third and the fourth parts of book are based on archive data.

All these major works represent Muhammad Mahdiev as a highly qualified, distinguished scientists and an assiduous analyst, a researcher, who thoroughly studied Tatar culture of the first half of the 20$^{th}$century. He informs his readers of interesting and memorable facts from the history of Tatar culture. When analyzing the activity of outstanding personalities, who made great contributions to Tatar development, he describes them as broad-minded, purposeful and humane people with a rich inner world.

M.Mahdiev's "Painting in a Fair Light" is the first attempt to study the history of Tatar culture in a methodological aspect which enables researchers and ordinary readers to access this invaluable information. During the first part of the 20th century the scholars studied, analyzed, and appreciated this information related to Tatar culture and press, preserved in Arabic, in archival documents and memories. M.Mahdiev's books describe the hard times, strong will and devotion of people loyal to their nation and its ideals. The books contain information on "historical" ethnography, literature, history of the nation, and statistics related to a wide cultural context, which makes them all an indispensable part of the century.

Muhammad Mahdiev's scientific heritage and his self-denying activity put him on a par with such famous Tatar people as Gail Rehimov, Gaziz Gubaydullin, and Dzhamal Velidi.

# М.С.МӘҺДИЕВНЕҢ «СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН…»: ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ ТАРИХЫННАН: ФӘННИ-ПУБЛИЦИСТИК МӘКАЛӘЛӘР ([ ТӨЗ. Г.ХӘСӘНОВА]. КАЗАН: ТАТАР.КИТ.НӘШР., 2014. 583 Б.) ФӘННИ БАСМАСЫНА БӘЯЛӘМӘ

**Дания Фатыйх кызы Заһидуллина,**
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе,
Россия, 420111, Казан ш., Бауман ур., 20 нче йорт,
zagik63@mail.ru.

Бәяләмәдә күренекле әдәбият галиме, язучы, энциклопедик мәгълүматлы шәхес Мөхәммәт Сөнгать улы Мәһдиевнең фәнни мирасын туплаган «Сызып ак нур белән…» хезмәте анализлана, шулай ук аның шәхесе, милләтнең мәдәни мирасын халыкка кайтару юлындагы көрәше билгеләнә. Рецензент М.Мәһдиевнең гыйльми һәм публицистик эшчәнлеге тармакларын, масштабын барлый, ул өйрәнгән шәхесләр һәм вакыйгаларны, галимнең аларга якын килү үзенчәлеген билгели. М.Мәһдиевнең мәкаләләре «көнитеш тарихы» («история повседневности») методологиясенә нигезләнеп язылганга күрә, аларда галим сүз алып барган заман, кешеләрнең тормышы-эшчәнлеге көнкүреш вакыйгаларында, детальләрдә, сурәтләрдә тасвирлана, реконструкцияләнә. Моннан тыш, әлеге методология милләт тарихындагы аерым чорларның психологик атмосферасын, фикри-гакълый халәтен, кешеләрнең яки милләтнең менталитетын, шул вакытта хөкем сөргән кичерешләр һәм омтылышларны аңларга, күңел аша уздырырга ярдәм итә.

Бәяләмә авторы М.Мәһдиевнең гыйльми-публицистик мирасына югары бәя биреп, язмаларның киң тарихи- мәдәни фонда яктыртылуына игътибар итә. Киңкырлы белемне язучы таланты белән куша алган М.Мәһдиевнең шәхесләр тарихыннан милләт тарихына хәрәкәт итүен билгели. Галимнең татар мәдәнияте тарихындагы урынын халкыбызның олы галимнәре, зыялылары, фикер ияләре Гали Рәхимнәр, Газиз Гобәйдуллиннар, Җамал Вәлидиләр белән бер биеклектә дип ассызыклый.

**Төп төшенчәләр**: татар әдәбияты белеме, «көнитеш тарихы», татарларның тарихи-мәдәни мирасы, Мөхәммәт Сөнгать улы Мәһдиев, гыйльми һәм публицистик эшчәнлек.

Мәдәни мирас дигән чиксез һәм бәһаләп бетергесез кыйммәтне бик күпләрнең акылы-рухы, хыялы-зәвыгы тудыра һәм туктаусыз баета. Кешелек дөньясын кешелеклелек чикләрендә саклап торган шушы байлык исә, үз чиратында, талант ияләреннән фидакарьлек тә, шәхси кыюлык та таләп итә. Мөхәммәт Сөнгать улы Мәһдиевнең фәнни мирасы тупланган «Сызып ак нур белән…» хезмәте (*Мәһдиев М.С. Сызып ак нур белән…: шәхесләребез тарихыннан: фәнни-публицистик мәкаләләр. Казан: Татар.кит.нәшр., 2014. 583 б.*) шушы фикерне ныгыта, тарихның аерым бер чорларында кеше акылы-хисе бар иткән мирасны дөньяга чыгаруның көрәшкә тиң булуын дәлилли.

«Милләт, халыкны исә көрәшчеләр генә алга алып бара». Бу – галимнең «Тарихи кыңгыравык» мәкаләсендә әйтелгән үз сүзләре, алар бүгенге вәзгыятьтә дә, фәнгә 1960 елларда, «Хрущев җепшеклеге» шартларында килеп, аннары «кырау төшкән буын» (Х.Туфан гыйбарәсе) язмышы мисалында да әһәмиятен югалтмый, галимнең үзенә, күпкырлы эшчәнлегенә, энциклопедик белеме-акылына, шәхси позициясенә бәя булып тора. М.Мәһдиевнең шушы киң колачлы, гыйльми нигезгә утыртылган фәнни мирасы – милләтнең узганы турындагы хакыйкатьне халыкка кайтару өчен көрәш мисалы. Ул совет чорында милли-мәдәни тарихның аерым бер сәхифәләрен өйрәнүнең шәхси батырлыкка тиң булуын раслый. Китапта, совет чоры галимнәре хезмәтләрендәге «ак таплар», бушлыклар, үз вакытында укучыга барып җитә алмаган бик күп материаллар урын ала.

Авторның, күпсанлы фактларны, вакыйгаларны, язмышларны эзләп табып, әдәби хәрәкәттә урыннарын билгеләп язган фәнни язмалары XX гасырның беренче чирегe татар мәдәнияте тарихын яктырталар. Аларны татар яңарышын әзерләгән, фикри күтәрелешкә зур өлеш керткән шәхесләребез тарихы дип тә карарга мөмкин булыр иде. Әлеге шәхесләр

исемлегендә «алтын чор»ны күзаллаган Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Баязитов, Г.Рахманколыйлар бар. XX гасыр башы күтәрелешенең үзәгендә кайнаган Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал, Ш.Камал, Г.Коләхмәтов һ.б. лар күпләгән шәхесләр тормышы һәм язмышы холык-фигыльләре, эш-гамәлләре, теләк-омтылышлары берлегендә тасвирлана. Татар фәне һәм мәдәниятенең «йөзек кашлары» – Г.Рәхим, Г.Гобәйдуллин, Җ.Вәлиди, Г.Сәгъди, Г.Нигъмәтиләр һ.б. эшчәнлеге, җентекле анализланып, югары бәя алган. Милли тарихта якты эз калдырган башка милләт кешеләре – татар мәгърифәтенә, мәдәниятенә, гыйлемгә хезмәт иткән матбагачы Иван Николаевич Харитонов (1859–1954), адвокат А.Г.Бать кебекләр дә олы рәхмәт хисләре белән искә төшерелә.

Гомумән алганда, бу җыентыкны 70-80 ел вакыт аралыгын колачлаган милли энциклопедия, татар халкы тарихындагы иң тынгысыз чорлар елъязмасы дип карап була. Ул, үз чиратында, һич тә тарихи фактлар җыелмасы кебек түгел, бәлки аяныч язмышлар, катлаулы холыклар, шәхси омтылышлар тупланмасы, шулай ук халыкка мәхәббәт, идеалларга тугрылык, дуслыкка хыянәт, гомуммилләт идеалларын шәхси амбицияләргә корбан итү, идеологик басымга яраклашу һ.б. бик күп мәсьәләләргә мисаллар җыелмасы төсле кабул ителә.

Мондый язмаларны гади укучыга кызыклы, мавыктыргыч форма табып җиткерүне фәндә «көнитеш тарихы» (история повседневности) дип йөртәләр. Бу методология тарихны көнкүреш хәлләрендә, детальләрдә, сурәтләрдә чагылдырырга, реконструкцияләргә мөмкинлек бирә. Үз чиратында, билгеле бер тарихи чорның психологик атмосферасын, фикри-гакълый халәтен, кешеләрнең яки милләтнең менталитетын, шул вакытта хөкем сөргән кичерешләр-омтылышларны аңлау, тою, теге яки бу вакыйгаларның эчке сәбәпләрен билгеләргә ярдәм итә. Мәсәлән, китаптагы тарихлар – Г.Тукай, Ф.Әмирхан яки М.Гафури һ.б. язмышлары – әдәби әсәрләр кебек укыла. Аларда шәхесләрнең холык-фигыле дә, яшәү тирәлеге дә образлы күрсәтелә, авторның шәхси бәясе, мөнәсәбәте туплап бирелә. Шуңа да Тукай язмышы («Габдулла Тукай турында замандашлар», 1962; «Шагыйрьнең бишеге», 1976) Казан арты төбәгенә, бу якның интеллектуаль куәтенә мәдхия булып яңгырый. Яки «Солтан Рахманколыйның иҗат эшчәнлеге» (1966), «Татар педагогикасы тарихында Рахманкуловлар» (1967) язмаларында аталы-уллы Габделмәннан һәм Солтан Рахманколыйларның гаять күпкырлы эшчәнлеге дә, гаиләдәге рухи хәл-халәт тә, туганнары, дуслары, танышлары, алар аралашкан шәхесләрнең башка татар зыялылары белән мөнәсәбәтләре дә бәян ителә; китаплары, төзегән сүзлекләре, тәрҗемәләре бәяләнә. Татар мәгърифәтчеләренең – «Ак нур сызып…» барган кешеләрнең - җыелма образы пәйда була.

Галим, конкрет вакыйгалар турында сүз алып барганда яки аерым шәхесләргә бер мәсьәлә аша караш ташлаганда да, материалларны башка мәгълүматлар белән баету юлларын таба, һәрчак киң тарихи-культурологик фонны сурәтләүгә аерым игътибар бирә. «Фатих Әмирхан жандармерия күзәтүе астында» (1976) дигән мәкалә, Татарстан милли архивы документларына нигезләнеп, язучыны махсус күзәтү-тикшерүләр, тентүләр турында сөйли. Бу хәлләрнең тамырлары каләмне Фатихның әтисе Зариф Әмирханның махсус күзәтүгә алынуы вакыйгаларына алып китә, Фатих исеме белән янәшә еш телгә алынган Әхмәтгәрәй Хәсәни язмышын бәян итүгә юл ача. Шулай ук язучының М.Вахитов белән мөнәсәбәтләренә игътибар бирелә. Шул рәвешле, татар зыялыларын махсус сак яки күзәтү астына алу, аның тарихы языла. Энциклопедик белемне язучылык сәләте, образлы сурәтләү белән бергә үреп файдаланган М.Мәһдиев шәхесләр тарихыннан милләт тарихына күпер ясый, һәр язмада, совет идеологиясенә җавап та, милли үзаңны, милли горурлыкны үстерүгә нигез дә булып, «халкым мескен булмаган» дигән лейтмотив фикер ярылып ята.

Хезмәтләр бер үк вакытта автор шәхесе, мәгълүматлылыгы хакында да сөйли. «Шагыйрьнең бишеге» (1976) мәкаләсендә, мәсәлән, этнографик һәм статистик мәгълүматлар, татарларның хөкүмәткә, чукындыруга каршы баш күтәрүләре тарихы, Наполеон армиясенә каршы көрәш вакыйгалары да, җирлектәге һөнәрләр, сәүдәгәрләр нәселләре тарихлары һәм мәктәп-мәдрәсәләр язмышы да, укымышлы кешеләр, Г.Тукай яшәгән төбәк галимнәре, аларның хезмәтләре дә, талант ияләренең әсәрләре дә, әдәбиятта һәм сәнгатьтә җирле тарихи вакыйгаларның чагылышы һәм тагын башка бик күп мәсьәләләр күтәрелә. Автор әйткәнчә,

«Казан арты биргән янтарь» Г.Тукайдан алып, Ш.Мәрҗанинең этисе Баһаветдин, бабасы Габденнасыйр, Г.Курсави, бу якта белем эстәгән Ә.Уразаев-Кормаши, Һ.Салихов, астрономия һәм астрология белгечләре Хәмзә Бәрәзәви, Фәйзулла бине Мортаза, мәгърифәтчеләрдән Ш.Күлтәси, Т.Яхин, Ф.Гобәев, Г.Мәхмүдев, К.Халиди, татар музыкасында җуелмас эз калдырган Х.Габәши, Х.Әхмәдуллин һәм башка бик күп шәхесләрнең якты образы барлыкка килә. Аерым кешеләр язмышында төбәк тарихы, татар халкы тарихы чылбыры хасил була.

Хезмәтнең аерым эзләнүләрнең язылу вакытына карап, хронологик тәртиптә төзелүе зур роль уйный. 1962-1968 еллар аралыгында язылып, шушы чор газета-журналларында басылган материаллар игътибарга лаек. Алар М.Мәһдиевнең Казан дәүләт университетында аспирантурада укыган елларында дөнья күрә башлый. 1964 елны Хатип Госман җитәкчелегендә «Татар совет әдәби тәнкыйте (1917–1932)» дигән темага якланган кандидатлык диссертациясе әдәбият белеме фәнендәге катлаулы, каршылыклы чорны колачлый. Яшь галимнең хезмәтендә 1917 елдан соңгы татар әдәби тәнкыйтенә тулаем караш ташлау; әдәби хәрәкәттә актив катнашкан шәхесләрнең абруйлы исемнәрен 1920–30 еллар һәм үз заманасы тәнкыйтенә кайтару, үзләренә лаек бәяне бирү, әдәбиятта урыннарын билгеләү омтылышы ясала. Шушы гаять җентекле, бай материал әдәбият тарихчысы М.Мәһдиевнең гомерлек темасына әверелә: ул, архив материалларына, XX йөз башы вакытлы матбугатына нигезләнеп, тирән эчтәлекле материаллар әзерләп бастыра, һәр язмасы белән әлеге теманың чикләрен киңәйтә. Бу чор күренекле галимнәре һәм тәнкыйтьчеләренең мирасын халыкка кайтаруның мөһимлеген ассызыклый.

Мәсәлән, «Галимҗан Нигъмәти турында кайбер яңа материаллар» (1965) язмасында мондый юллар бар: «Ләкин, кызганычка каршы, Галимҗан Нигъмәтинең тормыш юлы һәм иҗтимагый эшчәнлеге турында без бик аз беләбез; «Сайланма әсәрләр»дә аның тормыш юлы турында нибары бер бит материал бирелгән. Галимҗан Нигъмәтинең иҗтимагый эшчәнлеген ныклап өйрәнү аның әдәбият фәне өлкәсендәге хезмәтләрен яхшырак аңлау өчен дә ярдәм итәр иде». Бу сүзләр яшь галимнең үз алдына нинди максатлар куюы турында сөйли. М.Мәһдиев фәнни эзләнүләренең күп өлешендә гаепсезгә кара яла ягылган, милләт хәтереннән сызып ташларга хөкем ителгән шәхесләр яки күренешләр яктыртыла.

Тагын бер мисал. 1964 елны «Совет әдәбияты» журналында М.Мәһдиевнең «Габдрахман Сәгъди» дигән күләмле язмасы дөнья күрә. Монда күренекле галим, татарлардан беренче филолог-профессор Г.Сәгъдинең катлаулы тормыш юлы баскычлары, төп хезмәтләре күрсәтелә, аның эшчәнлегенә югары бәя бирелә. Әлеге язма 1930 елларда галимне эзәрлекләүләрдән соң язылган беренче зур хезмәт була.

Кызганычка каршы, М.Мәһдиев сүз алып барган, югары бәя биреп, мәдәниятебез тарихына кайтарган мондый исемнәр, әлеге язмышлар 1970 еллар «кыравы» шартларында кабат оныттырыла. Бу шәхесләрне, вакыйгаларны татар фәне 1990 елларда гына халыкка кире кайтара башлады. Шундый мәсьәләләрнең берсе – мәдрәсәләр тарихы. 1967 елны «Совет мәктәбе» журналында галимнең «Галия» мәдрәсәсе турындагы язмасы дөнья күрә, 1968 елны М.Мәһдиев Иж-Буби мәдрәсәсе тарихына, аны туздыру вакыйгасына багышланган зур хезмәт әзерли. Китапка аның кульязма хәлендә калган рус телендәге беренче варианты («Некоторые данные из истории Бобинской школы») урнаштырылган. Әлеге мәкалә М. Мәһдиевнең үз хезмәтенә рецензия язучы тарихчылар белән бәхәсен чагылдыра, «совет цензурасының» милли мираска мөнәсәбәтен күрсәтүе белән дә әһәмиятле. Монда XX йөз башында һәм 1920-30 елларда татар матбугатында Иж-Буби мәдрәсәсе тарихының өйрәнелү торышы шактый эзлекле китерелә, әлеге уку йортына, мөгаллимнәренә, Габдулла һәм Гобәйдулла Бубиларга кагылышлы бай материал тәкъдим ителә. М.Мәһдиев Казан губернасы жандарм управлениесе архивында сакланып калган материалларга – шәкерт дәфтәрләренә, сорау алу кәгазьләренә, тикшерү һәм суд эшләренә, бу хакта вакытлы матбугаттагы язмаларга мөрәҗәгать итә, А.Х.Мәхмүтованың эзләнүләрен файдалана, бу чорда цензура, яшерен күзәтүләр, җасуслык, провокаторлар мәсьәләләренә туктала, җәдит – кадим каршылыгы, Ишми ишан шәхесе турында җентекле күзәтүләре белән уртаклаша.

М.Мәһдиев татарларда гыйлем-мәгърифәт тарихын өйрәнүне гомеренең ахырына кадәр дәвам итә. Габдулла һәм Гобәйдулла Бубилар, Р.Фәхретдин, З.Камали, Г.Баруди, Ф.Кәрими

кебек шәхесләр хезмәт авторын сокландыра, аларның хезмәтләре кызыксыну уята. Ул мәктәп-мәдрәсә программалары һәм дәреслекләр, Габделмәннан Рахманколый һәм Таип Яхин китаплары, «Мөхәммәдия» кебек зур мәдрәсәләрдә укыту системасы хакында материаллар туплый, аерым өлешләрен вакытлы матбугатта бастыра.

Һәрвакыт галимнең игътибар үзәгендә булган, кабат-кабат әйләнеп кайтып өйрәнгән шәхесләре бар. М.Мәһдиев Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Рәхим, Г.Гобәйдуллин, С.Сүнчәләйләрнең язмышына кат-кат мөрәҗәгать итә, XX йөз башы татар милли-мәдәни хәрәкәте хакында яңа фактлар, яңа сызыклар барлыкка килә. Мәсәлән, Г.Рәхимнең 75 еллыгына әзерләнгән «Ерактан яңгыраган аваз» исемле күләмле язмада күренекле татар язучысы һәм галименең архив материалларына нигезләнеп тергезелгән тормыш юлы, әдәби иҗаты, этнография, әдәби тәнкыйть һәм әдәбият тарихы өлкәсендәге гаять мөһим эшчәнлеге, фаҗигале язмышы бәян ителә. Бер яктан, татар зыялылары белән горурлану, икенче яктан, ил тормышындагы 1917 ел инкыйлабы алып килгән үзгәрешләрнең милли күтәрелешне дә, аны әзерләгән олы шәхесләрне дә юк итүе фаҗигасенә төшенеп үкенү дулкынындагы мондый материаллар, күрәсең, идеологик чикләүләр эчендә яшәгән совет галимнәрен куркыта. Мәкалә 1971 елда университетның фәнни җыентыгында чыгарга тиеш булса да, басылмый кала. Советчыл идеологиянең җимерелүе 1990 еллардан башлап Гали Рәхимнең һәм башка «каһәрләнгән язмышлы» акыл ияләренең мирасын барлый башларга юл ача. М.Мәһдиев, мирас мәсьәләсен кабат-кабат күтәреп, Гали Рәхим, Җамал Вәлиди, Газиз Гобәйдуллин, Фатих Кәримиләр тормыш юлы һәм әдәби-гыйльми эшчәнлекләренең яңа якларын барлау эшенә керешә.

1970 еллар урталарыннан М.Мәһдиев башкарак характердагы материаллар әзерли башлый. «Фатих Кәриминең «Истанбул мәктүпләре» (1977) мәкаләсе докторлык диссертациясенең бер өлеше итеп уйланылган була. Татар әдәбияты тарихында беренче тапкыр Ф.Кәриминең юлъязмалар циклына төпле, тәфсилле анализ ясала. Бу материалда М.Мәһдиевне татар яңарышы, аны кузгаткан кешеләр, аларның фикер-карашлары кызыксындыра. 1980 елны, Мәҗит Гафуриның туууына 100 ел булуга багышлап, олы әдип иҗатына үзенчәлекле бәя бирелә. «Халык образы, ил язмышы мәсьәләсе М.Гафуриның бөтен иҗат нигезен тәшкил итте. Гомер йомгагының төп җепләреннән берсе дә әнә шул – Гафуриның үзен ил, халык язмышыннан аерылгысыз каравы», дип, галим бу иҗатны нәкъ шушы ноктадан анализлый. Бер үк вакытта М.Гафуриның татар әдәбиятындагы урыны хакында уйлана. Ул урынны бик хаклы билгели дә: «…поэтик осталык ягыннан Тукайның үз замандашы Гафуридан алдарак булуы фәндә беркайчан да бәхәс астына алынмады. Мәҗит Гафури шул ук вакытта С.Рәмиев һәм Дәрдемәнд шикелле «идеаль поэзия» вәкиле дә түгел. Гафури халыктан, шәкертләрдән, фәкыйрь крестьяннардан, һөнәрче, эшчеләрдән аерылгысыз. Аның шигырьләрендә бәхетсез фәкыйрьләрнең иңрәү авазларын, ачы язмыш ноталарын башка шагыйрьләрнең әсәрләренә караганда ешрак ишетәсең». Ф.Әмирханга багышланган шундый ук рухтагы материал башкачарак типта, анда, язучының иҗатыннан бигрәк, Ф.Әмирхан шәхесен, рухи бөеклеген ачу максаты куела. Бер яктан, автор Ф.Әмирхан тормышын үз нәсереннән өзек – «бәхет мөмкин була торып та, бәхетсез уздырган» яшьлек гыйбарәсе белән бәйли, акыллы, сәләтле, укымышлы Фатихның аяксыз калу фаҗигасен күрсәтә, ә икенче яктан, авыр сынауларга дучар ителгән әдипнең эшчәнлеге, иҗаты югары бәя ала.

1983 елда М.Мәһдиев Г.Камалның «Йолдыз» газетасындагы эшчәнлегенә багышланган зур мәкалә эшли, аны журналист буларак таныта. Аның татар матбугаты битләрендә Миргазиз Укмасыйга багышланган язмалары берничә тапкыр дөнья күрә. Галим Н.Думави, С.Сүнчәләйләрнең аерым әсәрләрен анализлап, аларның иҗатларын укучыга җиткерү мәсьәләсен көн тәртибенә куя.

М.Мәһдиевнең язмалары арасында, фәнни китапханәләрдә, архивларда утырып башкарылганнардан тыш,. шәхси танышлык, аралашу нәтиҗәсендә язылганнары да бар. Шундыйларның берсе Әхмәтгәрәй Хәсәни тормышына багышлана. «Гасыр» нәшриятын ачып, татар китабын бастыру эшенә зур өлеш керткән, татар матбугаты үсешендә яңа сүз булган «Аң» журналын оештырган Ә.Хәсәнине, аның ярдәмчесе һәм мәсләктәше Зәйнәп апаны нәкъ менә М.Мәһдиев татар укучысына яңадан ача. Ул Зәйнәп Хәсәнине тыңлап, блокнотлар тутыра. Репрессияләнгән асыл затлардан Мәхмүт Галәүнең хатыны Зәйнәпкә, Газиз

Гобәйдуллинның хатыны Рабигага, ирләре хакында мәгълүматлар сорап, хатлар яза. Соңрак, 1993 елда, ерактан, үткәннән килгән бу хәбәрләрне бастырып та чыгара.

М.Мәһдиевнең игътибар үзәгенә алынган шәхесләр арасында балалар язучысы Ф.Агиев, университет белемле, татар әдәбияты, әдәбият белеме хакында үткен мәкаләләр язган Н.Хәлфин, «Дим буенда» дигән гүзәл әсәр авторы Садри Җәләл, мәгърифәтче һәм дин белгече Габдеррәшид Ибраһимов та бар.

Бер үк вакытта бу чор язмаларында совет дәверенә, ул чактагы карашларга бәяләр дә күзәтелә. «Казан утлары» журналының 800 саны чыгуга багышлап язылган «Тарихыбыз көзгесе» (1989) мәкаләсендә мондый юллар бар: «Без байтак җимердек. … Ә журналистика, әдәбият тарихында «Шура»лар, «Аң»нар яши. Аралар ераклашкан саен бу журналларның тарихи әһәмияте тагын да ачыграк күренә бара: Риза Фәхретдинев, Габдулла Тукай, Җамал Вәлиди, Галимҗан Ибраһимов, Әхмәтгәрәй Хәсәни, Закир һәм Шакир Рәмиевләр эшчәнлегеннән башка журналистика һәм әдәбиятыбыз тарихын күз алдына китереп кара!».

Үзгәртеп корулар алып килгән фикер иреге М.Мәһдиев материалларын дөньяга чыгаруга юл ача. Галимнең XX йөз башына караган эзләнүләре һәрберсе бер докторлык диссертациясенә тиң зур фәнни хезмәтләр, монографияләр булып басылып чыга. Беренче җыентык («Әдәбият һәм чынбарлык: XX йөз башы татар әдәбияты тарихына яңа материаллар». Казан: Тат.кит.нәшр., 1987. 304 б.) татар әдәбияты һәм мәдәнияте тарихына караган күп кенә язмаларны берләштерә. М. Мәһдиев 1989 елны тагын бер монографиясен укучы хөкеменә тәкъдим итә («Реализмга таба: XX йөз башы татар әдәбиятында чынбарлыкның чагылышы мәсьәләләре». Казан: КДУ нәшр., 1989. 155 б.). Галим хезмәтнең «Әдәбият тарихы чыганагы буларак унынчы еллар татар вакытлы матбугаты» дигән беренче бүлегендә исемгә чыгарылган вакыт аралыгында таралган уннарча гәзит-журналларга гомуми күзәтү ясый, кайсы гәзит яки журналның нинди темаларны күтәрүен, аларда кемнәр эшләгәнлекне игътибар үзәгенә куя, әһәмиятле, актуаль мәкаләләргә тирән анализ бирә. «XX йөз башы татар әдәбиятында прототиплар. Аларны ачуның әһәмияте» дигән икенче бүлек авторның тагын бер фәнни «сукмакны» сала башлавы хакында сөйли. Әлеге проблеманы фәнни эшләү методикасын тәкъдим итеп, автор рус һәм Аурупа әдәбиятларында прототипларны билгеләүгә туктала. Г.Ибраһимов, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, М.Фәйзи әсәрләрендәге күп кенә геройларның прототиплары, аларның язмышы, әсәрләрнең язылу тарихы хакында бик күп кызыклы мәгълүматлар китерә. Китапның өченче бүлеге шулай ук аз өйрәнелгән катлам – XX йөз башында рәсем, опера, җыр, музыка сәнгатенә карый. Автор унынчы еллардан соң татар матбугаты битләрендә сәнгать һәм әдәбият арасындагы бердәмлекне теоретик нигезләүгә омтылыш ясалуын, әдәби процессны сәнгать алымнары белән якынайту эше колач җәюне күпсанлы мисаллар белән дәлилләп бирә. Бу бүлектә XX йөз башы татар мәдәнияте тирәнтен тикшерелә, дини һәм дөньяви бәйрәмнәр, әдәби-музыкаль кичәләр, татар яшьләрен берләштергән клублар, укучыга тәкъдим ителгән рәсем һәм җыр сәнгате, аерым бер сәнгать төрләрен үстерү өчен барган көрәш – бар да җентекле өйрәнелә.

1990 елны әлеге китапның дәвамы рәвешендә, рус телендә «Талантның социаль тамырлары» («Социальные корни таланта: из истории татарской литературы в годы нового революционного подъема и первой империалистической войны». Казань: Изд-во КГУ, 1990. 159 с.) дигән хезмәт басылып чыга. Китап XX йөз башы әдәбияты һәм мәдәнияте тарихын берничә проблема яктылыгында яктырта. Беренчесе – әдәбият һәм публицистикада дөньякүләм хәлләрнең чагылышы. Тагын бер өлкә – әдәбиятта «уртак ватан», рус-татар мөнәсәбәтләре – шулай ук кызыклы гомумиләштерүләргә китерә. К.Насыйри башлаган сөйләшүне 1913 елга китереп ялгый да, Мәһдиев бу мәсьәләдәге эволюцияне «татарларның мөселманлык дигән тар калып кысаларыннан чыгып, кешеләргә мөселман яки христиан итеп түгел, бәлки халык вәкиле буларак карарга өйрәнделәр» дигән нәтиҗә ясый. Китапның өченче-дүртенче бүлекләре тулысынча архив материалларына таянып язылган.

Әлеге зур фундаменталь хезмәтләр Мөхәммәт Мәһдиевне XX йөзнең беренче яртысы татар мәдәниятен колачлы, комплекслы өйрәнгән абруйлы галим, тырыш һәм киң карашлы тикшеренүче итеп таныта. Ул татар мәдәнияте тарихыннан иң кызык һәм сөендерә алырлык сәхифәләрне татар укучысына җиткерә, нәкъ ул, милли күтәрелешнең

башында торган, идеологлары булган шәхесләрнең бай рухи дөньясын, күзаллау киңлеген, максатчанлыгын һәм кешелек сыйфатларын калкытып, аларны милли тарихның түренә уздыра.

«Сызып ак нур белән…» хезмәте М.Мәһдиевнең, милли-мәдәни тарихны өйрәнү өчен, көнитеш тарихы методологиясенә татарлардан беренче булып мөрәҗәгать иткәнлеген ачыклый. Татар мәдәнияте тарихын, милли тарихны шәхесләр язмышы-тормышы аша өйрәнү, бәяләү галимгә белгечләр өчен дә, гади укучы өчен дә кызыклы гаять күп чыганакларны, мәгълүматларны фәнни әйләнешкә кертергә мөмкинлек бирә. Галим XX гасырның беренче чиреге татар мәдәниятенә кагылышлы материалларны, гарәп графикасында сакланган вакытлы матбугат язмаларын, архив документларын, истәлекләрне гади һәм үтемле рәвештә гыйльми эшкәртеп, бергә үреп карый һәм бәяли. М.Мәһдиев китапларында, аерым шәхесләрнең аянычлы-үкенечле язмышлары, аларның рухи көче һәм фидакарьлеге, көндәлек тормышы барланып, шәхес һәм яшәеш, халык өчен яшәү һәм иҗат итү, идеалларга тугрылык хакында фәлсәфи гомумиләштерүләр ясала. Һәр аерым «тарих» этнографик, әдәби, мәдәни, тарихи, статистик мәгълүматлардан үрелгән киң культурологик фонга килеп кушыла, тулы бер гасырның аерылгысыз өлешенә әверелә.

Фидакарь шәхес Мөхәммәт Мәһдиевнең фәнни мирасы, гыйльми эшчәнлеге аның исемен халкыбызның олы галимнәре, зыялылары, фикер ияләре Гали Рәхимнәр, Газиз Гобәйдуллиннар, Җамал Вәлидиләр белән бер биеклеккә күтәрә.

---

# РЕЦЕНЗИЯ НА НАУЧНОЕ ИЗДАНИЕ «МАГДЕЕВ МУХАММЕТ СУНГАТОВИЧ. ОЗАРИ ДУШУ СВЕТОМ… » (СОСТАВИТЕЛЬ ХАСАНОВА Г.М. КАЗАНЬ: ТАТАР.КН.ИЗД-ВО, 2014. 583 С.)

**Дания Фатиховна Загидуллина,**
Академия наук Республики Татарстан,
Россия, 420111, г. Казань, ул. Баумана, д. 20,
zagik63@mail.ru.

В рецензии анализируется издание, вобравшее в себя научные и публицистические труды знаменитого литературоведа, писателя, ученого с энциклопедическими знаниями Мухаммета Сунгатовича Магдеева, оценивается его жизнедеятельность и борьба за возвращение и введение в научный оборот национальных культурных ценностей. Автором рецензии рассматриваются основные направления и масштаб научных и публицистических изысканий М.С.Магдеева, определяются научные подходы к оценке событий и отдельных личностей. По мнению рецензента, труды ученого в методологическом плане написаны в русле «истории повседневности», поэтому в них историческое время реконструируется в деталях и образах, отражающих условия жизни, быт, влияющих на формирование сознания и мировоззрения. Кроме того, эта методология позволяет воссоздать психологическую атмосферу, интеллектуальное состояние, менталитет отдельных личностей и нации в целом, позволяет осознать и «пропустить через себя» переживания и стремления людей других эпох, в результате чего научные тексты становятся доступными для понимания широкому кругу читателя.

Рецензент высоко оценивает научно-публицистическое наследие М.С.Магдеева, обращает внимание на то, что исследования им велись на широком историко-культурологическом фоне. По мнению рецензента, направление изысканий ученого двигается от истории жизнедеятельности отдельных личностей – к истории нации. Место самого ученого определяется наряду с крупными учеными, интеллектуалами начала XX века – Гали Рахимом, Газизом Губайдуллиным, Джамалом Валиди.

**Ключевые слова**: татарское литературоведение, «история повседневности», историко-культурное наследие татар, М.С.Магдеев, научное и публицистическое наследие.